Ә.Н. ХУҖИӘХМӘТОВ



# ЗАМАНЧА УКУ-УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ



УДК 37.0(075.8)
ББК 74.202 я73
Х80

*Казан (Идел буе) федераль университетының психология һәм мәгариф институты гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә (беркетмә № 2, 26 февраль, 2015 ел).*

**Р е ц е н з е н т л а р:**
педагогика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе **В.Г. Гайфуллин;**
педагогика фәннәре докторы, профессор, Халыкара педагогик хезмәттәшлек академиясе академигы, Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы **Җ.Г. Нигъмәтов**

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

Х80 **Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**
**Заманча уку-укыту технологияләре:** югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы / Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2015. – 367 б.

**ISBN 978-5-00019-370-9**

Педагогика фәне яшь буынга белем бирү өлкәсендә куелган максат һәм бурычларны бүгенге көн чынбарлыгын исәпкә алып билгеләргә тиеш. Шуңа күрә әлеге хезмәттә педагогиканың гомуми нигезләре буларак аның төп төшенчәләре ачыклана, педагогик технологияләрнең тикшерену методлары яктыртыла, шулай ук укытучыларның һәм укучыларның эшчәнлеген оештыру мәсьәләләренә зур игътибар бирелә, укытуны интенсивлаштыру юллары бәян ителә, проблемалы һәм программалаштырылган укыту ысуллары ачыклана.

Мәгариф эшен оештыручыларга, укытучыларга, югары һәм махсус урта уку йортлары студентларына тәкъдим ителә.

**УДК 37.0(075.8)**
**ББК 74.202 я73**

**ISBN 978-5-00019-370-9**

**© Хуҗиәхмәтов Ә.Н., 2015**
**© Казан университеты нәшрияты, 2015**

## УКЫТУ ТӘГЪЛИМАТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРИНЦИПЛАРЫ

Укытуның теоретик нигезләрен педагогиканың дидактика дип аталган аерым бүлеге өйрәнә. Бу термин грек сүзеннән алынган, *өйрәтү, укыту* дигән мәгънәгә туры килә. Барлык фәннәрне укытуның гомуми теориясе *дидактиканың* төп бурычы булып тора. Аерым фәннәрне укытуның үзенчәлекләрен шул фәннәрнең методикасы өйрәнә.

Чех педагогы *Ян Амос Коменскийны* фәнни дидактикага нигез салучы дип саныйлар. Аның *«Бөек дидактика»* (1632) дигән китабында педагогиканың бу өлкәсе *«Бөтен кешене барысына да өйрәтүне гомуми сәнгате»* дип билгеләнә. XVIII гасырда Швейцария педагогы *И. Г. Пестало и* укыту-өйрәтү принциплары системасына нигез сала. XIX йөздә немец педагогы *А. Дистервег «Неме укытучылары өчен кулланма»* дигән хезмәтендә укыту процессын активлаштыру таләпләренең тулы бер комплексын тәкъдим итә.

Дидактиканың төп үзенчәлеге шунда: ул укыту процессын белем һәм күнекмәләрне формалаштыру чарасы дип кенә түгел, ә шәхесне һәрьяклап үстерүнең төп факторы итеп карый. Ул укыту һәм тәрбияне тулы бер педагогик процесс дип карый һәм тикшерә.

Дидактиканың кайбер аерым әһәмиятле төшенчәләрен карап үтик. Аларга түбәндәгеләрне кертәләр: *белем бирү, укыту, дәрес бирү, өйрәтү, укытуның закончалыклары һәм принциплары, укыту про ессы һәм аның компонентлары — бурычлар, эчтәлек, формалар, методлар, күрсәтмә чаралар, укытуның нәтиҗәсе* һ. б.

*Белем бирү* төшенчәсенә билгеле бер максатка юнәлдерелгән процессның һәм укучылар үзләштергән фәнни белемнәрнең нәтиҗәсе һәм шул нигездә формалашкан дөньяга карашлары, шәхеснең әхлак сыйфатлары, аның иҗади көче һәм сәләтенең үсешләре керә.

Белем бирү, нигездә, укыту тәэсирендә бара. Шул ук вакытта ул иҗтимагый тирәлек, массакүләм мәгълүмат һәм шәхеснең үзлегеннән укуы тәэсирендә дә тормышка ашырыла.

*Укыту* — ул укытучы һәм укучының максатчан эш итү процессы; беркадәр күләмдә белем алу, шәхеснең үсеше тормышка ашырыла. Укыту, билгеле, шәхеснең үсеш һәм аны тәрбияләү бурычларын тулысы белән хәл итә алмый. Шуңа күрә